ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады хакында

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе З.Р. Вәлиева тарафыннан тәкъдим ителгән «2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» докладны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына «2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладындагы Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карарга һәм алар буенча кирәкле чаралар күрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына һәм ведомстволарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына «2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 11 июне
№ 1001-VI ДС